**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет Урсаевского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитеты**

ул. Центральная, д. 65, село Урсаево,
Азнакаевского муниципального района, 423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

Үзәк урам, 65, Урсай авылы
Азнакай муниципаль районы, 423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от « 16» февраля 2021 г. № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 13.04. 5 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында» карары белән расланган,
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертү турында
(19.07.2018 № 11карар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2021 елның 04 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегия беркетмәсен үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 13.04. 5 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында» карары белән расланган,
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә (19.07.2018 №11 карар редакциясендә), 24 нче пунктны түбәндәге эчтәлелекле 7 нче пунктча белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«7) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычларның булмавы.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http//pravo.tatarstan.ru. веб – адресы буенча урнаштыру юлы белән һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында http//aznakayevo.tatar.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз естемдә калдырам.

Башлык З.Х.Рахимьянова